**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 20 апрелендәге 1276 номерлы карары**

## Ел саен үткәрелә торган «Минем шәҗәрәм» генеалогик тикшеренүләр республика конкурсының муниципаль этабын үткәрү турында

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының 2024 елның 1 мартындагы 38-од номерлы «Ел саен үткәрелә торган «Минем шәҗәрәм» генеалогик тикшеренүләр республика конкурсы турында»гы боерыгын тормышка ашыру һәм нәсел шәҗәрәсе традицияләрен саклау, гаилә бәйләнешләрен ныгыту һәм буыннар алмашын тәэмин итү максатыннан **карар бирәм**:

1. Әлеге карарның 1 номерлы кушымтасы нигезендә «Минем шәҗәрәм» генеалогик тикшеренүләр республика конкурсының муниципаль этабын үткәрү турында нигезләмәне расларга.

2. Ел саен үткәрелә торган «Минем шәҗәрәм» генеалогик тикшеренүләр республика конкурсының муниципаль этабында конкурс эшләрен бәяләү буенча конкурс комиссиясен төзергә һәм әлеге карарның 1 номерлы кушымтасы нигезендә аның составын расларга.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты җитәкчесе Б.Р.Алеевка йөкләргә.

**Җитәкче вазифаларын башкаручы –**
**беренче урынбасар** **А.Р.Нигъмәтҗанов**

Казан шәһәре Башкарма
комитетының 2026 елның
20 апрелендәге 1276 номерлы
карары белән расланган
1 номерлы кушымта

**Ел саен үткәрелә торган «Минем шәҗәрәм» генеалогик тикшеренүләр республика конкурсының муниципаль этабын үткәрү турында нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) ел саен үткәрелә торган «Минем шәҗәрәм» генеалогик тикшеренүләр республика конкурсының муниципаль этабын оештыру һәм үткәрү тәртибен билгели.

1.2. Ел саен үткәрелә торган «Минем шәҗәрәм» генеалогик тикшеренүләр республика конкурсының (алга таба – Конкурс) оештыручысы – Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты.

1.3. Конкурсның муниципаль этабын Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Аппараты» муниципаль казна учреждениесенең муниципаль архив идарәсе оештыра.

## II. Конкурсның максаты һәм бурычлары

2.1. Конкурсның муниципаль этабының төп максаты – генеалогик тикшеренүләр белән шөгыльләнүче талантлы катнашучыларны ачыклау һәм аларга ярдәм итү.

2.2. Конкурсның бурычлары:

- нәсел шәҗәрәсе төзү традицияләрен саклау һәм үстерү;
- гаилә тарихының ил һәм туган як тарихына кагылышын өйрәнү нигезендә балаларда һәм яшьләрдә патриотлык тәрбияләүгә ярдәм итү;
- буыннар арасында гаилә бәйләнешләрен һәм традицияләрен ныгыту;
- архив материаллары белән эшләүгә, тарихи һәм туган якны өйрәнү әдәбиятын укуга җәлеп итү.

## III. Конкурста катнашучылар

3.1. Конкурсның муниципаль этабында 4 яшь төркеме буенча барлык теләүчеләр катнаша ала:

- 1 нче төркем – гомуми белем бирү оешмаларының 1-4 нче сыйныф укучылары;
- 2 нче төркем –гомуми белем бирү оешмаларының 5-8 нче сыйныф укучылары;
- 3 нче төркем – гомуми белем бирү оешмаларының 9-11 нче сыйныф укучылары, шул исәптән 18 яшькә җиткәннәр;
- 4 нче төркем – һөнәри белем бирү оешмаларының 18 яшькәчә укучылары.

3.2. Конкурс эшләре яшь төркемнәре чикләрендә рейтингта беренче җиде позицияне алган муниципаль этапта катнашучылар конкурсның республика этабында катнашу өчен җибәрелә.

3.3. 14 яшьтән кечерәк катнашучының Конкурста катнашуга гаризасын ата-анасы (яисә законлы вәкиле) имзалый.

3.4. Конкурска, 1 нче яшь төркемендә катнашучылардан тыш, бары тик аерым тәртиптә генә башкарылган эшләр кабул ителә.

## IV. Конкурс комиссиясе

4.1. Конкурсның муниципаль этабын үткәрү һәм эшләрне сайлау максатыннан конкурс комиссиясе (алга таба – Комиссия) төзелә.

4.2. Комиссия түбәндәге функцияләрне үти:

- муниципаль этапта катнашучыларның конкурста катнашу турындагы гаризаларын җыю;
- конкурс эшләрен бәяләү;
- Конкурсның республика этабында катнашу өчен катнашучыларны сайлау;
- Комиссия беркетмәсе нигезендә Конкурсның республика этабында катнашу өчен җибәреләчәк катнашучылар исемлеген төзү;

4.3. Комиссия Казан шәһәре Башкарма комитеты вәкилләреннән һәм бәйсез экспертлардан (тарихчылар, туган якны өйрәнүчеләр, музей хезмәткәрләре) (килешү буенча) һәм рәис, рәис урынбасары, сәркатип һәм комиссия әгъзалары составында 9 кешедән төзелә.

4.4. Комиссия эше белән рәис җитәкчелек итә. Ул булмаган очракта бурычлар аның урынбасарына йөкләнә. Конкурс нәтиҗәләре белән шәхси кызыксынуы булган затлар Комиссия әгъзасы була алмый.

4.5. Комиссия эше аның утырышында алып барыла. Утырышта комиссия әгъзаларының гомуми саныннан кимендә өчтән икесе катнашса, утырыш тулы хокуклы дип санала.

4.6. Комиссия, Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты муниципаль этапны үткәрү срокларын билгеләгәннән соң, эш көннәрендә исәпләнә торган 14 көн эчендә конкурсның муниципаль этабына гаризалар һәм конкурс эшләре кабул итүне оештыра.

Конкурста катнашуга гаризаларны кабул итү һәм теркәүне комиссия секретаре гамәлгә ашыра.

4.7. Комиссия әгъзалары гаризалар кабул итү тәмамланганнан соң эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә конкурс эшләрен әлеге Нигезләмәнең VI бүлегендәге критерийлар буенча бәялиләр һәм конкурсның республика этабында катнашуга дәгъва кылучыларны билгелиләр.

4.8. Комиссия карарлары әлеге Нигезләмәнең VI бүлегендә күрсәтелгән критерийлар буенча комиссия әгъзалары куйган балларны кушу нәтиҗәләре буенча кабул ителә.

Конкурс йомгаклары буенча яшь төркемнәре чикләрендә рейтингта беренче җиде позицияне алган катнашучылар конкурста җиңүчеләр дип танлыла.

4.9. Комиссия карары беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм комиссия рәисе тарафыннан имзалана.

4.10. Конкурсның муниципаль этабын уздыру йомгаклары буенча Комиссия электрон рәвештә түбәндәге адреска: gen.kon@tatar.ru һәм/яки Столбище авылы, Совет урамы, 277 йорт («Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» ДБУ) адресы буенча «Минем шәҗәрә» тамгасы белән муниципаль этап җиңүчеләренең документлар җыелмасын җибәрә.

## V. Конкурсны үткәрү шартлары һәм тәртибе

5.1. Конкурс читтән торып үткәрелә. Конкурсның муниципаль этабын үткәрү даталары Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитеты тарафыннан раслана.

5.2. Конкурсның муниципаль этабында катнашу өчен комиссиягә электрон рәвештә arhiv.kazan@tatar.ru электрон почта адресына яки Комиссия

секретареның кулына тапшырып яки Казан шәһәре, Сигезенче Март ур., 5А йорт адресы буенча «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Аппараты» муниципаль казна учреждениесенең муниципаль архив идарәсенә почта аша гариза (әлеге Нигезләмәнең 1 номерлы кушымтасы) тапшырыла.

Конкурс эше, шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык (әлеге Нигезләмәнең 2 номерлы, 3 номерлы кушымталары) эш көннәрендә (дүшәмбе – җомга) сәгать 09:00 дән 17:00 гә кадәр (сәгать 12:00 дән 13:00 гә кадәр төшке аш) Казан шәһәре, Сигезенче Март урамы, 5А йорт адресы буенча Комиссия сәркатибенең кулына тапшырыла;

5.3. Конкурс материаллары яшь төркемнәре буенча түбәндәге форматларда тапшырыла:

- 1 нче төркем –катнашучы башкарган иҗади эш (гаилә агачы рәсеме, шәрехләр белән фотоальбомнар, коллажлар, схемалар, плакатлар, табигый материал һәм тукымалар кулланып ясалган күләмле эш һ.б.). Бер катнашучыдан керә торган эшләр саны чикләнмәгән;

- 2 нче төркем – катнашучы башкарган иҗади эш (гаилә агачы рәсеме, шәрехләр белән фотоальбомнар, коллажлар, схемалар, плакатлар, табигый материал һәм тукымалар кулланып ясалган күләмле эш һ.б.), һәм А4 форматындагы 10 биткә кадәр күләмле язма эш (реферат, эссе, сочинение һ.б.) [шрифты – 14 үлчәмдәге Times New Roman, кырлар сулдан – 2 см, уңнан – 1 см, өске һәм аскы кырлар – 2 см (битләрне нумерацияләү мәҗбүри)]. Кушымталар саны чикләнмәгән;

- 3 нче төркем – теләсә кайсы форматта башкарылган тикшеренү эшләре: язма эш, А4 форматындагы 15 биткә кадәр күләмле аналитик хисап [шрифты – 14 нче үлчәмдәге Times New Roman, кырлар сулдан – 2 см, уңнан – 1 см, өске һәм аскы кырлар – 2 см (битләрне нумерацияләү мәҗбүри)], видеоэш (гаилә тарихы турында 10 минутка кадәр озынлыктагы өй фильмы), Microsoft Power Point программасында презентация (50  лайдка кадәр);

- 4 нче төркем – архив документлары нигезендә башкарылган проект-тикшеренү эше (фәнни хисап, фәнни мәкалә, доклад).

5.4. Конкурска җибәрелгән эшләр редакцияләнми һәм рецензияләнми;

5.5. Документлар кабул итү вакытлары тәмамланганнан соң җибәрелгән гаризалар һәм конкурс эшләре каралмый;

5.6. Эшләр рус һәм (яки) татар телләрендә тапшырыла.

5.7. Муниципаль этапны үткәрү көннәре, конкурс документларын тапшыру вакытлары, сайлап алу шартлары һәм критерийлары турындагы

мәгълүмат, конкурс эшләрен кабул итә башлаганчы ун календарь көннән дә соңга калмыйча, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында урнаштырыла.

## VI. Конкурс эшләрен бәяләү критерийлары

6.1. 1 нче төркем эшләрен бәяләү критерийлары:

- конкурсның максатына һәм бурычларына туры килү (0 дән 10 баллга кадәр);
- эшне бизәүдә оригинальлек һәм иҗади якын килү (0 дән 10 баллга кадәр);
- идеяне техник яктан тормышка ашыру дәрәҗәсе (0 дән 10 баллга кадәр);
- конкурс эшен әзерләүдә мөстәкыйльлек дәрәҗәсе (0 дән 10 баллга кадәр);
- китерелгән тарихи фактларның дөреслеге (0 дән 10 баллга кадәр).

6.2. 2 нче һәм 3 нче төркем эшләрен бәяләү критерийлары:

- конкурсның максатына һәм бурычларына туры килү (0 дән 10 баллга кадәр);
- китерелгән тарихи фактларның дөреслеге, архив чыганакларын куллану дәрәҗәсе (0 дән 10 баллга кадәр);
- гаилә кыйммәтләрен һәм традицияләрен ачу дәрәҗәсе (0 дән 10 баллга кадәр);
- үз шәҗәрәләре буенча тикшерелгән буыннар саны (0 дән 10 баллга кадәр);
- фамилиясенең килеп чыгышы, ата-бабаларының милли тамырлары, кайсы конфессиягә караганлыгы турында белешмәләрнең барлыгы һәм нигезләнгән булуы (0 дән 10 баллга кадәр);
- нәсел вәкилләренең ил һәм туган як тарихында һәм тормышында роле турында тарихи белемнәр (0 дән 10 баллга кадәр);
- эшнең сәнгати сыйфатлары (әдәби тел, сурәтләүнең образлылыгы, күргәзмә материалларның бизәлеш сыйфаты) (0 дән 10 баллга кадәр);
- кулланыла торган тарихи чыганакларның төрлелеге (документлар, хатлар, гаилә риваятьләре һ.б.).

6.3. 4 нче төркем эшләрне бәяләү критерийлары:

- үз фамилияннең килеп чыгышы, милли тамырлар, ата-бабаларыңның кайсы конфессиягә каравы, аларның тормыш эшчәнлеге турында нигезле

мәгълүматларны да кертеп, проблеманы тикшерүнең тулылыгы (0 дән 10 баллга кадәр);

- чыганакларга сылтамалар белән тарихи мәгълүматларның төгәллеге һәм үз шәҗәрәсе буенча үз нәтиҗәләре (0 дән 10 баллга кадәр);

- һәркем файдалана алырлык төп архив чыганакларын колачлау, зур күләмдә файдаланылган әдәбият (0 дән 10 баллга кадәр);

- материал структурасының төгәллеге һәм бәян итүнең мантыйкка туры килүе (0 дән 10 баллга кадәр);

- эшнең гамәли һәм фәнни әһәмияте (0 дән 10 баллга кадәр).

## VII. Нәтиҗәләр ясау

7.1. Конкурсның муниципаль этабында җиңүчеләр һәр яшь төркеме буенча аерым билгеләнә.

7.2. Конкурс эшләрен бәяләү комиссия әгъзалары тарафыннан әлеге Нигезләмәнең VI бүлегендә билгеләнгән бәяләү критерийлары нигезендә эксперт бәяләве ысулы белән гамәлгә ашырыла.

7.3. Комиссия әгъзалары 10 баллы шкала кысаларында (0 дән 10 баллга кадәр) бәяләүнең һәр критерие буенча баллар куялар, шуннан соң баллар бергә кушыла. Бәяләү нәтиҗәләре аерым бәяләү кәгазьләренә кертелә, алар Комиссия әгъзасының шәхси имзасы белән раслана һәм Комиссия рәисенә тапшырыла (әлеге Нигезләмәнең 4 номерлы кушымтасы).

7.4. Комиссия әгъзалары тарафыннан әлеге Нигезләмәнең VI бүлегендә күрсәтелгән критерийлар буенча куелган балларны кушу нәтиҗәләре буенча һәр яшь төркеме буенча катнашучыларның йомгаклау рейтингы төзелә. Рейтингны Комиссия рәисе һәм әгъзалары имзалый.

7.5. Конкурс йомгаклары буенча яшь төркемнәре чикләрендә йомгаклау рейтингында беренче җиде позицияне алган катнашучылар Конкурста җиңүчеләр дип таныла.

7.6. Конкурска йомгаклар Комиссия әгъзалары тарафыннан конкурс эшләрен бәяләү тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә уздырыла торган комиссия утырышында ясала.

Утырыш уздырылган көнне Комиссия конкурс нәтиҗәләре турында яшь төркемнәре чикләрендә җиңүчеләр турында белешмәләр булган беркетмә төзи (әлеге Нигезләмәнең 5 номерлы кушымтасы).

Беркетмә комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана, комиссия рәисе тарафыннан раслана, әлеге Нигезләмәнең 5 номерлы кушымтасында китерелгән форма буенча рәсмиләштерелә.

7.7. Әгәр конкурс эше тапшырылмаса һәм шәхси белешмәләрне эшкәртүгә ризалык бирелмәсә, Комиссия конкурсның муниципаль этабында катнашуга гаризаны карап тикшерүгә кабул итми.

7.8. Гомуми рейтинг түбән булган очракта (эшне бәяләү яшь төркеме чикләрендәге барлык критерийлар буенча бәяләрнең гомуми суммасының яртысыннан түбәнрәк, конкурс эшләренең конкурс таләпләренә һәм конкурсның сайлап алу критерийларына туры килмәве) аерым яшь төркемендә конкурсның муниципаль этабы уздырылмаган дип санала.

## VIII. Йомгаклау нигезләмәләре

8.1. Әлеге Нигезләмә рәсми басылып чыккан вакыттан гамәлгә керә.

8.2. Тапшырылган эшләргә авторлык хокуклары Конкурс катнашучыларында кала.

8.3. «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Аппараты» муниципаль казна учреждениесенең муниципаль архив идарәсе конкурс эшләрен, шул исәптән конкурс гаризалары белән җибәрелгән фотосурәтләрне, видеороликларны һәм башка документларны, архив чараларын алга этәрү максатыннан, авторлык хокуклары сакланган очракта мәгълүмат һәм презентация материаллары ясау өчен куллану хокукын үзендә калдыра.

Нигезләмәгә
1 номерлы кушымта
(Форма)

**Ел саен үткәрелә торган «Минем шәҗәрәм» генеалогик тикшеренүләр республика конкурсының муниципаль этабында катнашу өчен гариза**

| | |
|---|---|
| Фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) | |
| Катнашучы вәкиленең фамилиясе, исеме, атаның исеме (булган очракта) | |
| Катнашучының яше | |
| Катнашучы укый торган белем бирү оешмасы | |
| Катнашучының тулы йорт адресы, индексы | |
| Катнашучының элемтә өчен телефоны | |
| Катнашучының E-mail ы | |
| Конкурс эшенең атамасы | |
| Эш тапшырылган яшь төркеме | |

Нигезләмәгә
2 номерлы кушымта
(Форма)

## Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык

Мин, ______________________________________________________________________,
(конкурста катнашучының Ф.И.А. (соңгысы — булган очракта) тулысынча)

______________________________________________________________________
укучы, элемтә өчен телефоным: __________________, 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында»гы федераль законның 9 статьясы нигезендә үз теләгем белән һәм үз мәнфәгатьләремне яклап «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Аппараты» муниципаль казна учреждениесенең муниципаль архив идарәсенә (алга таба – Оператор) конкурста катнашучыларның мәгълүмат базасын булдыру, конкурс казанышлары һәм җиңүчеләре турында мәгълүматны Операторның сайтларында (http://kzn.ru) урнаштыру максатыннан ел саен үткәрелә торган «Минем шәҗәрәм» генеалогик тикшеренүләр республика конкурсының муниципаль этабын үткәрү чикләрендә, автоматлаштыру чараларын кулланып, шулай ук әлеге чараларны кулланмыйча шәхси мәгълүматларымны эшкәртүгә ризалык бирәм.

Әлеге документ белән Операторга түбәндәге шәхси мәгълүматларымны эшкәртүгә ризалыгымны бирәм:

1. Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта).
2. Элемтә өчен телефон номерым.
3. Белем бирү оешмасының атамасы.
4. Социаль статусым.

Мин бары тик түбәндәге максатлар өчен генә шәхси мәгълүматларымны файдалануга ризалык бирәм:

- эшне формалаштыру һәм эшкәртү;
- тапшырылган конкурс материалларын карап тикшерү;
- статистика алып бару;
- конкурс нәтиҗәләрен Операторның рәсми сайтында бастыру;
- югарыда күрсәтелгән максатлар белән бәйле башка гамәлләр.

Ел саен уздырыла торган «Минем шәҗәрәм» генеалогик тикшеренүләр республика конкурсы турында басылып чыккан язмалар кысаларында матбугат басмаларында, Интернет челтәрендә, радио һәм телевидение эфирында урнаштырыла торган мәгълүмат материалларында һәм башка материалларда үз сурәтләремне куллануга ризалык бирәм.

Сурәтләр минем намусымны, абруемны һәм эшлекле дәрәҗәмне төшерүче ысуллар белән файдаланыла алмый.

Шәхси мәгълүматларны эшкәртү турындагы әлеге ризалык тапшырган вакыттан гамәлдә була һәм, Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә Операторга гади язма формада гариза тапшырып, минем тарафтан кире кайтарып алынырга мөмкин.

20_____ елның «_____» _________________ ________________________
(конкурста катнашучының имзасы) (фамилия, инициаллар)

Документ создан в электронной форме. № 53625-Инф от 16.05.2026. Исполнитель: Переводчики
Страница 11 из 16. Страница создана: 15.05.2026 16:33
ЕМСЭД

Нигезләмәгә
3 номерлы кушымта
(Форма)

**Шәхси мәгълүматлар субъекты тарафыннан**
**таратырга рөхсәт ителгән шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык**

Мин, ___________________________________________________________________________,
(шәхеси мәгълүматлар субъектының Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта) тулысынча)
элемтә өчен телефоным: _____________, электрон почта адресым: ___________________, 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында»гы Федераль законның 10 нчы статьясы нигезендә, «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Аппараты» муниципаль казна учреждениесе (ИНН 1655065522, ОГРН 1051622218471, урнашкан урыны: Казан шәһәре, Кремль урамы, 1 йорт) (алга таба – Оператор) тарафыннан ел саен үткәрелә торган «Минем шәҗәрәм» генеалогик тикшеренүләр республика конкурсы кысаларында Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында түбәндәге тәртиптә урнаштыру максатыннан минем шәхси мәгълүматларымны таратуга ризалыгымны бирәм:

| **Шәхси мәгълүматлар-ның категориясе** | **Шәхси мәгълүматлар исемлеге** | **Таратырга рөхсәт итәм (әйе/юк)** | **Чикләнмәгән сандагы кешеләргә таратырга рөхсәт итәм (әйе/юк)** | **Шартлар һәм тыюлар** | **Өстәмә шартлар** |
|---|---|---|---|---|---|
| Гомуми шәхси мәгълүматлар | Фамилиясе | | | | |
| | Исеме | | | | |
| | Атасының исеме (булган очракта) | | | | |
| | Белем бирү оешмасы | | | | |
| | Социаль статусы | | | | |
| Биометрик шәхси мәгълүматлар | Кашнашучының йөзе сурәтләнгән төсле цифрлы фотографик сурәт | | | | |

Шәхси белешмәләр субъектының шәхси белешмәләреннән чикләнмәгән затлар даирәсенә файдалану мөмкинлеге бирелә һәм башка гамәлләр башкарыла торган Операторның мәгълүмат ресурслары турындагы белешмәләр:

| **Мәгълүмат ресурсы** | **Шәхси мәгълүматлар белән башкарыла торган гамәлләр** |
|---|---|
| http://kzn.ru | Чикләнмәгән сандагы кешеләргә бирелү |

Әлеге ризалык минем тарафтан ирекле рәвештә бирелде һәм 20 __ елның «___» __________ алып 20__ елның «___» __________ кадәр гамәлдә.

Минем шәхси мәгълүматларымны таратуны туктатуны таләп итү хокукын үземдә калдырам. Таләп алынган очракта Оператор минем шәхси мәгълүматларны таратуны кичекмәстән туктатырга, шулай ук шәхси мәгълүматлар тапшырылган өченче затлар исемлеген хәбәр итәргә тиеш.

20_____ елның «_____» _________________ ___________________________________
(конкурста катнашучының имзасы) (фамилиясе, инициаллары)

Нигезләмәгә
4 номерлы кушымта
(Форма)

**Ел саен уздырыла торган «Минем шәҗәрәм» генеалогик тикшеренүләр республика конкурсы муниципаль этабының конкурс эшләренә аерым бәяләү кәгазьләре**

Эшләрне аерым бәяләү кәгазьләре (1 нче төркем)

| Гариза бирүченең Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта), конкурс эшенең аталышы һәм эшне тапшыру форматы | |
|---|---|
| Критерийлар | 0 дән 10 баллга кадәр |
| Конкурсның максатына һәм бурычларына туры килү | |
| Эшне бизәүдәге үзенчәлек һәм иҗади якын килү | |
| Идеяне техник яктан тормышка ашыру дәрәҗәсе | |
| Конкурс эшен әзерләүдә мөстәкыйльлек дәрәҗәсе | |
| Китерелгән тарихи фактларның дөреслеккә туры килүе | |
| Барлыгы | |

Эшләрне аерым бәяләү кәгазьләре (2 нче, 3 нче төркем)

| Гариза бирүченең Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта), конкурс эшенең аталышы һәм эшне тапшыру форматы | |
|---|---|
| Критерийлар | 0 дән 10 баллга кадәр |
| Конкурсның максатына һәм бурычларына туры килү | |
| Китерелгән тарихи фактларның дөреслеге, архив чыганакларын файдалану дәрәҗәсе | |
| Гаилә кыйммәтләрен һәм йолаларын ачу дәрәҗәсе | |
| Үз нәселе буенча тикшерелгән буыннар саны | |
| Үз фамилиясенең килеп чыгышы, милли тамырлары, ата-бабаларның кайсы конфессиягә каравы турында мәгълүматларның булуы һәм нигезлелеге | |

Документ создан в электронной форме. № 53625-Инф от 16.05.2026. Исполнитель: Переводчики
Страница 13 из 16. Страница создана: 15.05.2026 16:33
ЕМСЭД

| | |
|---|---|
| Нәсел вәкилләренең ил һәм туган як тарихында һәм тормышында роле турында тарихи белемнәр | |
| Критерийлар | 0 дән 10 баллга кадәр |
| Эшнең сәнгать ягыннан кыйммәте (әдәби тел, бәян итүнең образлылыгы, күргәзмә материалларны бизәү сыйфаты) | |
| Кулланыла торган тарихи чыганакларның төрлелеге (документлар, хатлар, гаилә риваятьләре һ.б.) | |
| Барлыгы | |

Эшләрне аерым бәяләү кәгазьләре (4 нче төркем)

| Гариза бирүченең Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта), конкурс эшенең аталышы һәм эшне тапшыру форматы | |
|---|---|
| Критерийлар | 0 дән 10 баллга кадәр |
| Үз фамилиясенең килеп чыгышы, милли тамырлары, ата-бабаларының кайсы конфессиягә каравы, аларның тормыш эшчәнлеге турында нигезле мәгълүматларны да кертеп, мәсьәләне тикшерүнең тулылыгы | |
| Чыганакларга сылтамалар белән, үз нәселе буенча тарихи мәгълүматларның төгәллеге һәм үзе чыгарган нәтиҗәләр | |
| Барлык төп ачык архив чыганакларын колачлау һәм кулланылган әдәбият күләме | |
| Структураның ачыклыгы һәм материалны бирүнең мантыйкка туры килүе | |
| Эшнең практик һәм фәнни әһәмияте | |
| Барлыгы | |

20___ елның «___» __________ ______________ ________________
(төзү датасы) (комиссия әгъзасының имзасы) (имзаның аңлатмасы)

Нигезләмәгә
5 номерлы кушымта
(Форма)

**Ел саен үткәрелә торган «Минем шәҗәрәм» генеалогик тикшеренүләр республика конкурсының муниципаль этабындагы конкурс эшләрен бәяләү буенча конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсе**

«Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Аппараты» муниципаль казна учреждениесе муниципаль архив идарәсенең почта адресы: ______________________________,
(индекс, шәһәр, урам, йорт)
e-mail: ______________________________________.

«Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Аппараты» муниципаль казна учреждениесе муниципаль архив идарәсе башлыгының Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта) (тулысынча), телефон: ____________________________________________________________
______________________________________________________________________________.

Конкурсның муниципаль этабының конкурс комиссиясе рәисенең Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта) (тулысынча): _______________________________________________.

Утырыш көне: __________________________________________________________________.

Конкурсның республика этабына түбәндәге эшләрне тәкъдим итәргә:

1 нче яшь төркеме: ______________________________________________________________
______________________________________________________________________________;
(эшнең аталышы, Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта), авторның туган елы)

2 нче яшь төркеме: ______________________________________________________________
______________________________________________________________________________;
(эшнең аталышы, Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта), авторның туган елы)

3 нче яшь төркеме: ______________________________________________________________
______________________________________________________________________________;
(эшнең аталышы, Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта), авторның туган елы)

4 нче яшь төркеме: ______________________________________________________________
______________________________________________________________________________.
(эшнең аталышы, Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта), авторның туган елы)

Комиссия әгъзаларының имзалары:

________ ______________________________________________________
(имза) (Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта), вазифасы)

________ ______________________________________________________
(имза) (Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта), вазифасы)

________ ______________________________________________________
(имза) (Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта), вазифасы)

Беркетмә расланды ______________________________________________________
(муниципаль этапның конкурс комиссиясе рәисе имзасы)

Документ создан в электронной форме. № 53625-Инф от 16.05.2026. Исполнитель: Переводчики
Страница 15 из 16. Страница создана: 15.05.2026 16:33
ЕМСЭД

Казан шәһәре Башкарма
комитетының 2026 елның
20 апрелендәге 1276 номерлы
карары белән расланган
2 номерлы кушымта

**Ел саен үткәрелә торган «Минем шәҗәрәм» генеалогик тикшеренүләр республика конкурсының муниципаль этабындагы конкурс эшләрен бәяләү буенча конкурс комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| Г.Р.Мусина | конкурс комиссиясе рәисе, «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Аппараты» муниципаль казна учреждениесенең муниципаль архив идарәсе башлыгы |
| Н.И.Казаринова | конкурс комиссиясе рәисе урынбасары, «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Аппараты» муниципаль казна учреждениесенең эш башкару идарәсе башлыгы |
| О.Н.Спиридонова | конкурс комиссиясе секретаре, «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Аппараты» муниципаль казна учреждениесенең муниципаль архив идарәсе башлыгы урынбасары |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Г.Ф.Хәсбиуллина | «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Аппараты» муниципаль казна учреждениесенең контроль һәм коррупциягә каршы эш идарәсе башлыгы |
| Л.Ш.Шәфигуллина | «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Аппараты» муниципаль казна учреждениесенең муниципаль архив идарәсе башлыгының беренче урынбасары |
| Р.Р.Гусарова | «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Аппараты» муниципаль казна учреждениесенең муниципаль архив идарәсендәге шәхси состав буенча документлар белән эшләү бүлеге башлыгы урынбасары |
| Г.А.Сәлахова | «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Аппараты» муниципаль казна учреждениесенең муниципаль архив идарәсендәге Казан шәһәренең архив фондын формалаштыру бүлеге консультанты |
| А.Л.Карбаев | «Казан шәһәре музей комплексы» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| А.М.Елдашев | төбәкне өйрәнүче, тарихчы (килешү буенча) |